КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 6 октябрь г.Казань № 800

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында Ятмас Дусай – Шепшеңәр төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен юридик затлар милкендә (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре милекчесе) булган, кушымтада күрсәтелгән 6 093 778 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләреннән барлыкка килә торган 35 021 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләрен (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районындагы Ятмас Дусай авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлекләре милекчеләренә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен түләү күләмен билгеләгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында килешүләр (алга таба – килешүләр) әзерләүне һәм аларны алына торган җир кишәрлекләре милекчеләренә җибәрүне;

килешүләр төзүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлекләре милекчеләре тарафыннан имза куелган килешүләр законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

3. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы чикләрендә урнашкан, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында Ятмас Дусай – Шепшеңәр автомобиль юлын реконструкцияләү өчен планлаштыру проектын һәм межалау проектын раслау турында» 2023 елның 17 августындагы 458 номерлы карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты нигезендә алына торган җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләрен башкаруны;

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә алына торган җир кишәрлекләре өчен түләүләр күләмен билгеләүне.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 6 октябрь, 800 нче
карарына кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алынырга тиешле җир кишәрлекләре исемлеге

| Кадастр номеры | Урнашу урыны | Мәйданы, кв.метр | Алына торган мәйдан, кв.метр | Милекчесе |
|---|---|---|---|---|
| 16:23:270102:16 | Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Ятмас Дусай авыл җирлеге | 141 822 | 3 245 | «Урал» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте |
| 16:23:000000:223 | Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Ятмас Дусай авыл җирлеге | 1 328 776 | 26 447 | «Урал» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте |
| 16:23:000000:1716 | Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Ятмас Дусай авыл җирлеге | 4 623 180 | 5 329 | «Вахит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте |
| Барлыгы | | 6 093 778 | 35 021 | |